**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**(Кырык икенче утырыш)**

**28 июль 2025 ел** **№ 323** **Теләче ав.**

Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 30 мартындагы 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә премия һәм матди ярдәм түләү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә түләүләрне җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы прокуратурасының 2025 елның 11 июнендәге 02-08-01-2024/159-25-20920037 номерлы протестын карап, Теләче муниципаль районы Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 30 мартындагы 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә премия һәм матди ярдәм түләү тәртибе турында нигезләмәгә (2023 елның 23 июнендәге 1903 номерлы карар редакциясендә), 2.3 пунктны түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2.3. Премияләр бирү ай, квартал, ел эш йомгаклары буенча башкарыла. Эш йомгаклары буенча премия күләме бер ел эчендә вазыйфаи затның айлык хезмәт хакы күләмен тәшкил итә, бер ай һәм квартал өчен эш йомгаклары буенча премия күләме, әлеге Нигезләмәнең 2.4 пункты белән билгеләнә.

Премияләр түләнергә мөмкин:

1) һөнәри яисә дәүләт бәйрәмнәренә бәйле рәвештә;

2) дәүләт бүләкләре, дәүләт билгеләрен алган өчен;

3) волонтерлык хәрәкәтендә актив катнашкан өчен;

4) һөнәри конкурсларда, республика, федераль дәрәҗәдәге спорт

ярышларында ирешкән нәтиҗәләр өчен;

5) республика, федераль дәрәҗәдәге сайлауларны оештыруда һәм үткәрүдә актив катнашкан өчен.

Премияләр турында карар Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм боерык белән рәсмиләштерелә.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Башлыгы




А. Г. Фәтхуллин